Минзәлә муниципаль районының
Әтрәкле авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от «27» март 2020 ел №9

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Әтрәкле авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында"гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми тестә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Газизянов Р.Ш.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Өтрәкле авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27.03. 2020 ел. N 9

ТР Минзәлә муниципаль районы Өтрәкле авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, БВС һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш), аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Өтрәкле авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

4. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

5. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Өтрәкле авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

6. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Өтрәкле авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

7. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

8. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ______________ Минзәлә муниципаль районы Өтрәкле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис.

____________________________________________

Адресы:

____________________________________________

____________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________ срокка кадәр ______________________ чараларны гамәлгә

______________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:__________________

Түләү алучы банкның БИК

____________________________________________

Сч. N ___

____________________________________________

Кабул итүче Сч. N ______________________________

КПП ______________________________________

КБК ______________ ОКАТО _________________

Түләү билгеләнеше

____________________________________________

Җитәкче _______________ ___________________________

М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N ________________

Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында

_____________________

____________________________________________

(муниципаль берәмлек атамасы)

суммада ________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис.

____________________________________________

Адресы:

____________________________________________

Алдым "___" _______________ 20___ ел. _____________________________

_____________________

(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.